Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлеге составына керүче Мельничный Починок авыл җирлегендә гражданнар җыены **КАРАРЫ**

11 ноябрь 2020 ел № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Урахча авыл җирлеге составына керүче Мельничный Починок авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2021елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең Мельничный Починок , Наратлы авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

- авыл җирлеге чигендәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту һәм төзекләндерү өчен;
- Мельничный Починок авылындагы басманы төзекләндерү өчен;
- Мельничный Починок авылындагы чишмәне төзекләндерү өчен;
- авыл җирлеге чигендәге су белән тәэмин итү җайланмаларын тәртиптә тоту өчен (суэтем башняларына тирәнлек насослары сатып алу өчен);
- Уракчы авылында Геройлар Аллеясы төзү;
- авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру: урамнарны төзекләндерү һәм карап тоту.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Урахча авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Уракчы авылы, Совет урамы, 36Айорт; Мельничный Пүчинкәсе авылы, Киров урамы, 20Б йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Гәрәев Ф.М.

Уракчы авыл җирлеге башлыгы: Гәрәев Ф.М